| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 апрель № 272

г. Казань

2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын әзерләү графигын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыр КАРАР БИРӘ:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын әзерләү графигын (алга таба – График) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына үз юнәлешләре буенча фараз күрсәткечләрен «Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба – Система) График белән билгеләнгән вакытлар нигезендә кертүне тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын әзерләү өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары соратулары буенча билгеләнгән тәртиптә җибәрүне;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына 2017 – 2019 елларга фараз күрсәткечләрен Системага График белән билгеләнгән вакытлар нигезендә кертүне гамәлгә ашыруны;

Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына 2017 – 2019 елларга җитештерү-финанс эшчәнлегенең фараз күрсәткечләрен Системага кертүне гамәлгә ашыруны.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков